Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Каракашлинская основная общеобразовательная школа»
Ютазинского муниципального района Республики Татарстан

РАССМОТРЕНО
Протокол заседания ШМО учителей начальных классов
от 23.08.2023 г. №1
Руководитель
_______Нагимова И.С.
подпись

СОГЛАСОВАНО
Заместитель директора
по учебной работе
__________Ахметова Э.Ф.
«24»августа 2023 г.

УТВЕРЖДАЮ
директор МБОУ
« Каракашлинская ООШ»
___________М.Ш.Закиров
Приказ № 71 от
«24» августа 2023 г..

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
учебного предмета
## «ПО ЛИТЕРАТУРНОМУ ЧТЕНИЮ НА РОДНОМ ЯЗЫКЕ»

для начального общего образования
уровень образования

Класс: 4
Срок освоения программы: 1 год
Составитель: Мурасова Г.Р.

ПРИНЯТА на заседании
педагогического совета
протокол № __ от
«24 » августа 2023 г.

2023 г.

## Аңлатма язуы

## Программа түбәндәге норматив документларга нигезләнеп язылды:

1. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль Закон, 2012. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы законы, 2013 ел.
2. ТР Ютазы муниципаль районының “Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль юджет белем бирү учреждениясенең 2023-20204нче уку елына кабул ителгән укыту планы
3. **Дәреслек:** Г.Сафиуллина,М.Гарифуллина.,Ә Мөхәмәтҗанова.,Ф.Хәсәнова 3 кисәктә Казан, “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты

### Укыту программаларында шәхси, предмет һәм метапредмет нәтиҗәләре.

**Башлангыч сыйныфны бетергәндә** укучы төп мәктәп программасын үзләштерергә әзер була, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шактый белем туплый.
- текст өстендә эшли ала: кирәкле информацияне эзләп таба, урынлы куллана белә: дәреслектә иркен ориентлаша, берничә чыганактан мәгълүмат туплый, сүзлекләр белән эш итә, вакытлы матбугатка күзәтү ясый һәм мәктәп китапханәсе фондыннан файдалана;
- әдәбиятның сүз сәнгате булуына инана, мәгълүматлар туплый;
- әдәби әсәрләр аша әхлак нормаларының үтәлешенә ирешә;
- әдәби әсәрләрне анализлый, аларга дөрес бәя бирә белә.

.

### 4 нче сыйныфны тәмамлаганда универсаль укыту гамәлләре формалаштыруда көтелгән нәтиҗәләр

**Гомуми танып белү эшчәнлеге өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр**

• дәреслектә бирелгә текст, сүзлекләр белән иркен эш итәргә, кирәкле сүзне эзләп табарга, мәгънәсен ачыкларга;

• дәреслектә ориентлашырга, шартлы билгеләрне яхшы белергә, текстны эзләгәндә “Эчтәлек” бите белән эшли белергә, төс белән аерылган текст фрагментларын табарга, махсус билгеләнгән информацияләр белән эш итәргә;

• текст өстендә эшләргә, тема һәм төп мәгънәне ачыкларга, вакытлы матбугат белән эшләргә,

• берничә төрле информация чыганаклары белән эшли белергә (дәреслек, мөстәкыйль эш дәфтәре һәм хрестоматия, дәреслек һәмсүзлекләр, иллюстрацияләр һәм картиналар, комплектта булган башка дәреслекләр (әйләнә-тирә дөнья), китапханәдән алынган китаплар, Интернет материаллары.

**Коммуникатив уку гамәлләре өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр:**

• партадашы белән кечкенә һәм зур төркемнәрдә эшли белергә, инсценировкалар вакытында төрле рольләрне башкара белергә;

• ике төрле караш булганда бер фикергә килә белергә,үз фикерен әсәрдән өзекләр белән ныгытырга, иптәшләре җавапларын игътибар белән тыңларга;
• әсәр геройларының фикерләрен таба белергә, үз фикерен әйтергә һәм башка фикерләр белән уртак нәтиҗәгә килергә.

**Контроль һәм үзконтроль өлкәсендә**

**укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала;**

• әйтелгән фикерне раслау өчен, тексттан өземтәләр китерергә, соңгы нәтиҗәнең дөреслегенә инанырга, җавапларга үзбәя бирә белергә һәм иптәшләренең җавапларын бәяләргә.;

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны.**

Әдәби уку филология фәннәре өлкәсенә керә.

IV сыйныф – 1 сәгать – 34 сәгать.

**Әдәби укуга 4 нче сыйныфта укыту планында атнага 1 сәгать вакыт бирелгән, программа 34 сәгатькә исәпләп төзелде.**

| № | Бүлекнең исеме | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | ***Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез*** | 7 |
| 2 | ***Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра.*** | 5 |
| 3 | ***Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез.*** | 4 |
| 4 | ***Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз*** | 3 |
| 5 | ***Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышабыз*** | 5 |
| 6 | ***Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә***? | 5 |
| 7 | ***Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз.*** | 2 |
| 8 | ***Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз*** | 3 |
| | | 34 |

**Әдәби уку дәресләре программасы, 4 нче сыйныф (34 сәг)**

**Халык авыз иҗаты**

**Мифлар турында гомуми кузаллау булдыру.** Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы кузаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы, тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә, максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы). Халыклар әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.**

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлятьар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгзн вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре**

Автор әкиятләренең халык әкиятләре белән охшашлыгы. (жанр һәм сюжет). Халык әкиятләрендәге тылсым белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя**

Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыруны дәвам итү**.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой характерының катлаулылыгы, вакыт белән бәйләнеше. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел бериәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында**

Шагыйрь, язучы, рәссамнарның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылышы;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. Әсәр авторлары турында мәгълүмат туплау.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

Тематик планлаштыру 4 сыйныф

| № | Бүлек. Дәрес темасы | Сәг саны |
|---|---|---|
| | ***1.Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез*** | |
| **1** | Җир йөзендә яшәгән беренче кешеләр. Җир ничек барлыкка килгән? | 1 |
| 2 | Борынгы легендалар ни сөйли? Тотем агачлар | 1 |
| 3 | Пәйгамбәрнең тууы. Туган як сылуы – ак каен | 1 |
| 4 | Абага чәчәге. | 1 |
| 5 | Тотем хайваннар. Татар мифологиясендә Ак бүре. Татарстан гербы. | 1 |
| 6 | Ак бүре (Татар халык әкияте) Әкиятләрдә ак елан. | 1 |
| 7 | Еланнар патшасы Шаһмара. “Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан ки-череп, бүгенге тормыш белән бәйлибез”темасын йомгаклау | 1 |
| | ***2.Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра.*** | |
| 8 | Борынгы шагыйрь Кол Гали. Кыссаи Йосыф. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Без – татар балалары.<br>Галимҗан Латыйп. “Минем нәсел” | 1 |
| 10 | Нәсел агачы. | 1 |
| 11 | Су асты патшалыгында. Су кызы. | 1 |
| 12 | Айсылу – бәхетле бала. | 1 |
| ***3.Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез.*** | | |
| 13 | Җирдә миңа ни кирәк? Шәехзадә Бабич шигырьләре. | 1 |
| 14 | Көзге табигать мизгелләре.<br>Кышкы сандугач.<br>Иртә яме, иртә моңы- җан азыгы. | 1 |
| 15 | Әнкәм портреты.<br>Иң матур сүз. | 1 |
| 16 | Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә.<br>Газаплы язмыш. | 1 |
| ***4.Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз.*** | | |
| 17 | Кечкенә хезмәтче.<br>Күз яшьле балачак. | 1 |
| 18 | Каникуллар- рәхәт вакыт.<br>Балачак хатирәләре. | 1 |
| 19 | Матурлык дөньяны коткара.<br>Көннәрем гөрләп торсын. | 1 |
| ***5.Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышабыз*** | | |
| 20 | Каен – урман чибәре.<br>Бөтен дөнья ак кына. | 1 |
| 21 | Язгы моң.<br>Серле күк. | 1 |
| 22 | Матурлык дөньясы.<br>Идел көзгесендә. Туган як. | 1 |
| 23 | Туган көнгә-салават күпере.<br>Табигать – серле дөнья. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Аккошлар-сак кошлар. | |
| 24 | Сандугач – табигать җырчысы.<br>Урман докторы. | 1 |
| **6.Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә?** | | |
| 25 | Кирлемән маҗаралары | 1 |
| 26 | Тылсымлы, кодрәтле үлән.<br>Гөмбәләр серен белү кирәк. | 1 |
| 27 | Бану әби сабагы.<br>Аш пешерү хикмәтләре.<br>Татар халык ашлары. | 1 |
| 28 | Балалар дөньясы. | 1 |
| 29 | Бүрек-нәни көчек.<br>Бүрек-ышанычлы сакчы. | 1 |
| ***7.Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз.*** | | |
| 30 | Язучы катнашында үткән “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы.Бәбкә үстерү кыенлыклары<br>Чыпчыкның да үз җыры бар | 1 |
| 31 | Яз галәмәтләре<br>Һәркемгә үз Ватаны кадерле<br>Татарстан флагы | 1 |
| **8.Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк. Туган як турында уйланабыз** | | |
| 32 | Зур тарихлы батыр халкым | 1 |
| 33 | Балачакның онытылмас мизгелләре<br>Сөю-иң куатле дәва. | 1 |
| 34 | “Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз”бүлеген йомгаклау.Йомгаклау контроль эше. | 1 |

В данной рабочей программе по литер. чт. на родном языке пронумеровано прошнуровано и скреплено печатью МБОУ «Каракашлинская ООШ» 7 (семь) страниц

Директор школы ________ Закиров М.Ш.